КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 637

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибен раслау хакында» 2019 ел, 30 апрель, 371 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга

авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибен раслау хакында» 2019 ел, 30 апрель, 371 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 28 ноябрь, 1524 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрне ачыклау тәртибен раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $3^1$ һәм 5 статьяларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрне ачыклау тәртибен расларга.»;

2 пунктта «Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклауда» сүзләрен «ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрне ачыклауда» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын махсуслаштырылган торак урыннары наймы шартнамәсе буенча яллаучы булып торган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән затларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш шартларын җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге турында таныклаучы хәлләрне ачыклау тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга авыр тормыш ситуациясен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген раслый торган хәлләрне ачыклау тәртибе»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан булган затларның торак урынга хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Респуб-

ликасы Законының (алга таба – Закон) 5 статьясындагы 1 һәм $5^2$ өлешләре нигезендә эшләнгән, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затларга, алар арасындагы һәм 23 яше тулган затларга авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган шартларны ачыклау механизмын билгели һәм авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган шартлар исемлеген билгели.»;

түбәндәге эчтәлекле 1.3 пункт өстәргә:

«1.3. Әлеге Тәртипнең гамәлдә булу көче кагыла торган гражданнар категорияләре һәм авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуын яисә булмавын билгеләү өчен нигезләр:

махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучы ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затлар – Законның 5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә махсуслаштырылган торак урынына наем шартнамәсенең биш ел гамәлдә булу срогы чыгуга бәйле рәвештә;

махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучы ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затлар, алар арасындагы һәм 23 яше тулган затлар – Законның 5 статьясындагы $5^2$ өлеше нигезендә махсуслаштырылган торак урынына наем шартнамәсенең гамәлдә булу срогын киметү турында гариза биргән очракта;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затлар, алар арасындагы һәм 23 яше тулган затлар – «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль законның $8^1$ статьясы, Законның $3^1$ статьясы нигезендә төзекләндерелгән торак урынны милеккә сатып алу өчен яки заемга алучының йөкләмәсе ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен түләү бирүгә гариза биргән очракта.»;

2.1 пунктта «ятим балаларга» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән затларга» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 һәм 2.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән затлар махсуслаштырылган торак урыннарга наем шартнамәләре гамәлдә булу срогы тәмамланганга кадәр өч ай кала, ә әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар махсуслаштырылган торак урынга наем шартнамәсе гамәлдә булу срогын киметү турындагы гариза белән бергә Министрлыкка әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуын яисә булмавын раслый торган документларны (алга таба – документлар) җибәрә.

Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән затлар Министрлыкка «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль законның $8^1$ статьясы, Законның $3^1$ статьясы нигезендә төзекләндерелгән торак урынны

милеккә сатып алу яки заемга алучының йөкләмәсе ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча торак урын сатып алуга бирелгән кредитны (заемны) тулысынча каплау өчен түләү (алга таба – түләү) бирүгә гариза белән бергә документлар җибәрә.

Документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән фактларны раслау яисә кире кагу өчен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә мәгълүмат ала, шулай ук, мәгълүмат сорату һәм алу юлы белән Тәртипнең 1.2 пунктында билгеләнгән бер яисә берничә хәлне ачыклау буенча җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

2.3. Махсуслаштырылган торак урыннарга наем шартнамәләре гамәлдә булу срогы тәмамланырга 60 көн кала комиссия әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән махсуслаштырылган торак урыннарга наем шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак урыннарын наемга алучыларның кергән документларын карап тикшерә һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуы яки булмавы турында хисап төзи.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4 пункт өстәргә:

«2.4. Комиссия әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән затлардан кергән документларны аларның Министрлыкка керү даталарыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча карап тикшерә һәм комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан кул куела торган авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуы яисә булмавы турында Министрлыкка мотивлаштырылган хисап тапшыра.

Министрлык авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуы яисә булмавы турындагы хисап нигезендә авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булуы яисә булмавы турында мотивлаштырылган бәяләмә чыгара, алар ачыкланган очракта бәяләмәдә Тәртипнең 1.2 пунктында каралган һәм ачыкланган хәлләр исемлеген, шулай ук хисап алынган датадан бер эш көне эчендә аларны ачыклауга нигез булып хезмәт иткән документларны күрсәтә.

Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән затка карата чыгарылган әлеге мотивлаштырылган бәяләмәне Министрлык аны чыгару датасыннан бер эш көне эчендә түләү бирү турында карарлар кабул итү буенча комиссиягә җибәрә.»;

3.1 пунктта:

беренче абзацта «махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын наемга алучыларга» сүзләрен һәм «ятим балаларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «(әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга карата)» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «(әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга карата)» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «ятим балаларның» сүзләрен «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән затларның» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын наемга алучылар» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән затларга карата бәяләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль законның 81 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затларга төзекләндерелгән торак урынын милеккә сатып алуга яисә заемга алучының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча кредитны (заемны) тулысынча каплауга түләүләр бирүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2023 елның 21 декабрендәге 2227 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» Федераль законның $8^1$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән затларга төзекләндерелгән торак урынын милеккә сатып алуга яисә заемга алучының йөкләмәләре ипотека белән тәэмин ителгән шартнамә буенча кредитны (заемны) тулысынча каплауга түләүләр бирүгә гариза тапшыру һәм карап тикшерү һәм кабул ителгән карар турындагы мәгълүматны җибәрү тәртибенең 4 пунктында билгеләнгән документларга ясалган анализны исәп алып төзелә.»;

3.2 пунктның беренче абзацында «бәяләмә» сүзе алдына «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга карата» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта «бәяләмә» сүзе алдына «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга карата» сүзләрен өстәргә;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләрнең булмавы ачыкланган очракта, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затлар били торган торак урыннарны социаль наемга алу шартнамәләре төзелә.

Әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеген таныклый торган хәлләр булганда, махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре Министрлык һәм әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затлар тарафыннан яңа биш ел срокка төзелә, әлеге срок чыкканнан соң әлеге Тәртип нигезендә әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга авыр тормыш хәлен җиңүдә ярдәм күрсәтү кирәклеге булу яисә булмауны таныклый торган хәлләр кабат ачыклана.»;

3.5 пунктта:

беренче абзацта «ятим балаларга» сүзен «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затларга» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» сүзләрен «Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, алар арасыннан затларның торак урынына хокукларын гамәлгә ашыру турында» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «ятим балалар» сүзен «әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Махсуслаштырылган торак урынына наем шартнамәсенең гамәлдә булу срогын киметү турында гаризаны канәгатьләндерү хакында карар кабул ителгән очракта, әлеге Тәртипнең 1.3 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән затлар белән махсуслаштырылган торак урыннарына социаль наем шартнамәләренә кул кую ике нөсхәдә махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләрен өзү датасыннан икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин